Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге Советының кырык җиденче утырышы

Колай авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

16 июнь, 2025 ел № 127

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советы бишенче чакырылыш депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3, 6, 7 пунктлары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2, 4 өлешләре, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге уставының 13 статьясы нигезендә Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советының бишенче чакырылыш депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.

2. «Алга» («Вперед») басмасында әлеге карарны кабул ителгән көненнән биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башлыгы Н.В. Поповская